ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2024 ел, 23 сентябрь N 218

"Апас шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советының 2021 елның 7 декабрендәге 71 номерлы карары белән расланган "Апас шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

60 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«60.Планнан тыш күчмә тикшерү, 248 - ФЗ Федераль законының 1 өлешендәге 3-6 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә үткәрелгән очраклардан тыш, прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин.

Урынга барып тикшерү уздыру турында контрольдә тотылучы затка, әгәр контроль төре турындагы Федераль законда башкасы каралмаган булса, әлеге Федераль законның 21 статьясында каралган тәртиптә урынга барып тикшерү уздыру турындагы карарның күчермәсен җибәрү юлы белән ул башланырга егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.»;

62 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"62. Барып тикшерү нәтиҗәләре буенча 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел.".

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

"Апас шәһәр тибындагы поселогы"

муниципаль берәмлеге башлыгы

Апас шәһәр җирлеге Советы Рәисе А.Г. Җиһаншин